ГЛАВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ
ВЕТЕРИНАРИИ
КАБИНЕТА МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР
КАБИНЕТЫНЫҢ
БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.04.2019 Казан № 51-од

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентын раслау турында» 2013 елның 27 маендагы 165-п номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең (алга таба – ТР МК БВИ) «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентын раслау турында» 2013 елның 27 маендагы 165-п номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары Г.Г.Мотыйгуллинны җаваплы итеп билгеләргә.»

2. ТР МК БВИнең 2013 елның 27 маендагы 165-п номерлы боерыгы (ТР МК БВИнең 19.01.2015 № 6-п, 15.12.2015 № 534-п, 12.07.2016 № 257-п, 08.12.2016 № 513-п боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектә:

1.2 пунктының өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тикшерүләрнең бердәм реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – тикшерүләрнең бердәм реестры), «Контрольлек (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына, «Татарстан Республикасы йогынты актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына тиешле мәгълүматны кертү билгеләнгән тәртиптә ТР МК БВИнең вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан башкарыла.»;

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. ТР МК БВИ тарафыннан дәүләт функциясе түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Евразия икътисадый комиссиясе советының «Таможня берлегенең «Сөтнең һәм сөт ризыкларының куркынычсызлыгы турында» техник регламенты турында» (ТР ТС 033/2013) 2013 елның 9 октябрендәге 67 номерлы карары (алга таба – Таможня берлегенең «Сөтнең һәм сөт ризыкларының куркынычсызлыгы турында» техник регламенты) (Евразия икътисадый комиссиясе советының рәсми сайты http://www.eurasiancommission.org/, 14.10.2013);

Евразия икътисадый комиссиясе советының «Таможня берлегенең «Итнең һәм ит ризыкларының куркынычсызлыгы турында» техник регламенты турында» 2013 елның 9 октябрендәге 68 номерлы карары (ТР ТС 034/2013) (Евразия икътисадый комиссиясе советының рәсми сайты http://www.eurasiancommission.org/, 11.10.2013);

Евразия икътисадый комиссиясе советының «Евразия икътисадый берлегенең «Балык һәм балык ризыкларының куркынычсызлыгы турында» техник регламенты хакында» 2016 елның 18 октябрендәге 162 номерлы карары (ТР ЕАЭС 040/2016) (Евразия икътисадый комиссиясе советының рәсми сайты http://www.eaeunion.org/, 20.03.2017);

Таможня берлеге комиссиясенең «Таможня берлегенең «Куркынычсыз азык-төлек продукциясе турында» техник регламентын кабул итү турында» 2011 елның 9 декабрендәге 880 номерлы карары (ТР ТС 021/2011) (Таможня берлеге комиссиясенең рәсми сайты http://www.tsouz.ru/, 15.12.2011);

Таможня берлеге комиссиясенең «Таможня берлегенең «Май-терлек мае продукциясенә техник регламент» техник регламентын кабул итү турында» 2011 елның 9 декабрендәге 883 номерлы карары (ТР ТС 024/2011) (Таможня берлеге комиссиясенең рәсми сайты http://www.tsouz.ru/, 15.12.2011);

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (алга таба – РФ КоАП) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, № 1, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Җинаять кодексы (алга таба – РФ ҖК) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1996, № 25, 2954 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законы (Ведомости Съезда народных депутатов Российской Федерации и Верховного совета Российской Федерации, 1993, № 24, 857 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Азык-төлек продуктларының сыйфаты һәм куркынычсызлыгы турында» 2000 елның 2 гыйнварындагы 29-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2000, № 2, 150 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 59-ФЗ номерлы федераль закон)(Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 19, 2060 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, № 52, 6249 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дару чаралары әйләнеше турында» 2010 елның 12 апрелендәге 61-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 16, 1815 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 473-ФЗ номерлы федераль закон) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2014, 29 декабрь, бастырып чыгару номеры: 0001201412290024, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сыйфатсыз һәм хәтәр азык-төлек чималына һәм азык-төлек продуктларына экспертиза уздыру, аларны куллану яки юк итү турында нигезләмә раслау хакында» 1997 елның 29 сентябрендәге 1263 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1997, № 40, 4610 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Түләүле ветеринария хезмәтләрен күрсәтү кагыйдәләрен раслау турында» 1998 елның 6 августындагы 898 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1998, № 33, 4012 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Азык-төлек продуктларының сыйфатына, куркынычсызлыгына һәм халык сәламәтлегенә мониторинг оештыру һәм уздыру турында» 2000 елның 22 ноябрендәге 883 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2000, № 48, 4701 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Азык-төлек продуктларының сыйфатлы һәм куркынычсыз булуын тәэмин итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге һәм контрольлеге турында» 2000 елның 21 декабрендәге 987 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2001, № 1 (II кисәк), 123 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ветеринариядә наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр куллану турында нигезләмә раслау турында» 2004 елның 3 сентябрендәге 453 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2004, № 37, 3733 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хайваннарның аеруча хәтәр авыру чыганакларын юкка чыгарганда хайваннарны читләштерү һәм терлекчелек продуктларын тартып алу турында» 2006 елның 26 маендагы 310 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 23, 2502 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 28, 3706 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, № 19, 2825 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар тарафыннан алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентларына карата уздырыла торган уртак планлы тикшерүләр турында» 2015 елның 22 октябрендәге 1132 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 2015 елның 22 октябрендәге 1132 номерлы карары (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2015, 26 октябрь, бастырып чыгару номеры: 0001201510260012);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан документларга һәм (яисә) мәгълүматларга, шул исәптән электрон рәвештә, шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмаларга гарызнамәләр җибәрү һәм аларны түләүсез нигездә алу турында» 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 323 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016 № 17, 2418 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) аерым төрләрен оештырганда куркынычка юнәлтелгән алым куллану һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 17 августындагы 806 номерлы карары («Юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның эшчәнлеген һәм (яки) алар тарафыннан кулланыла торган җитештерү объектларын куркынычлылыкның билгеле бер категориясенә яки хәтәрлекнең билгеле бер классына (категориясенә) кертү кагыйдәләре» белән берлектә) (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 806 номерлы карары) (РФ законнары җыентыгы, 29.08.2016, № 35, 5326 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтүләр төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүләргә ризасызлыклар бирү һәм аларны карап тикшерү, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 166 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2017, № 8, 1239 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2018 елның 21 апрелендәге 482 номерлы карары (алга таба – РФ

Хөкүмәтенең 482 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2018, № 18, 2633 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында шушы документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалардан сорала һәм алына торган документлар һәм (яки) мәгълүматлар исемлеген раслау турында» 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы боерыгы (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 724-р номерлы боерыгы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, № 18, 2647 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы)(Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан 2009 елның 13 маенда 13915 номеры белән теркәлгән) (Российская газета, 2009, 14 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Терлекчелектә барлыкка килгән сыйфатсыз һәм хәтәр продукциягә ветеринар-санитар экспертиза, аны куллану яки юк итү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген уздыру буенча күрсәтмә раслау турында» 2008 елның 6 маендагы 238 номерлы боерыгы (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан 2008 елның 9 июлендә 11946 номерлы белән теркәлгән) (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, 2008, № 30);

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Гражданнарның шәхси хуҗалыкларында һәм ачык типтагы кошчылык хуҗалыкларында кошлар асрауның ветеринария кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 3 апрелендәге 103 номерлы боерыгы (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, 2006, № 19);

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Ябык типтагы кошчылык предприятиеләрендә кошлар асрауның ветеринария кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 3 апрелендәге 104 номерлы боерыгы (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, 2006, № 19);

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Ветеринария өлкәсендә лаборатор тикшеренүләр уздыру кагыйдәләрен раслау турында» 2008 елның 5 ноябрендәге 490 номерлы боерыгы (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, 2008, № 52);

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Чит илләрдән ит һәм ит чималы кертүгә, эшкәртүгә, саклауга, бер урыннан икенче урынга алып баруга һәм сатуга ветеринария күзәтчелеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2007 елның 29 декабрендәге 677 номерлы боерыгы (Российская газета, 2008, № 64; Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, 2010, № 25);

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Россия Федерациясе территориясенә сәнәгый яки җылылык белән эшкәртелмәгән терлекчелек промыселы продуктларын һәм аларны беренчел эшкәртү продуктларын кертү (чыгару), эшкәртү, бер урыннан икенче урынга алып бару, сатуның ветеринария кагыйдәләрен раслау турында» 2008 елның 6 октябрендәге 453 номерлы боерыгы (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, 2008, № 47);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Россия Федерациясе территориясендә, Ерак Көнчыгыш федераль округы территориясеннән тыш, оештырылган алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан планнан тыш тикшерүләр уздыруны килештерү тәртибен раслау турында» 2016 елның 12 декабрендәге 817 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 817 номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 21 март, бастырып чыгару номеры: 0001201703210041, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Баш дәүләт ветеринария инспекторы тарафыннан расланган Терлекчелек продуктларын эшкәртү һәм саклау предприятиеләрендә дәүләт ветеринария күзәтчелеге бүлекчесе турында нигезләмә 14.10.1994 № 13-7-2/173 (Российские вести, 1995, № 5);

«Татарстан Республикасында ветеринарлык эше турында» 1993 елның 13 июлендәге 1934-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Югары Советы җыелма басмасы, 1993, № 6-7; Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2000, № 10 (8), кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2003, №5, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе структурасын раслау турында» 2012 елның 24 февралендәге ПУ-148 номерлы Указы (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2012, № 2, 212 ст.);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе мәсьәләләре» 2012 елның 10 мартындагы 202 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 24.04.2012, № 31, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге турында нигезләмә раслау турында» 2013 елның 16 августындагы 563 номерлы карары (алга таба – 563 номерлы ТР МК карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы», 23.08.2013, № 63, 1988 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы йогынты актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2013 елның 23 августындагы 593 номерлы карары (алга таба – 593 номерлы ТР МК карары)(«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2013, № 65, 2059 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында куркынычка юнәлдерелгән алым кулланыла торган төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләре исемлеген раслау турында» 2018 елның 27 сентябрендәге 856 номерлы карары (алга таба – 2018 елның 27 сентябрендәге 856 номерлы ТР МК карары)(Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2018, № 77, 2491 ст.).»;

1.5 пунктта:

беренче абзацта «юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның эшчәнлеге,» сүзләреннән соң «, шул исәптән 473-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентлары булып торучы (алга таба – юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар),» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резиденты статусы бирелгән юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге гамәлгә ашырылганда 473-ФЗ номерлы федераль закон нигезләмәләре исәпкә алына.»;

1.6.2 пунктчаның уникенче абзацына «294-ФЗ номерлы федераль законда һәм 473-ФЗ номерлы федераль законның 24 статьясында билгеләнгән» сүзләрен өстәргә;

1.6.2 пунктчада уналтынчы абзацны төшереп калдырырга;

1.6.3 пунктчаның дүртенче абзацында «һәм Россия Федерациясе законнарына туры килми торган» сүзләрен «, шулай ук зарури үтәлеше Россия Федерациясе законнарында каралмаган норматив документларның таләпләре үтәлешен» сүзләренә алмаштырырга;

1 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле $1.7^{1}$ пункт өстәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан федераль округ территориясендә, федераль округлар территорияләрендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләрен оештыру өлкәсендә вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы вәкиле (алга таба – вәкаләтле федераль орган) һәм (яки) алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе идарәче компаниясе вәкиле урынга чыгып уртак планлы тикшерү уздырылганда катнашырга мөмкин.»;

1.8 пунктта «294-ФЗ номерлы федераль законның $13^{3}$ статьясы һәм РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә тикшерүләрнең бердәм реестрына

кертелгән тиешле мәгълүмат» сүзләрен «294-ФЗ номерлы федераль законның 13$^3$ статьясы һәм РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә кертелгән; РФ Хөкүмәтенең 482 номерлы карары нигезендә «Контрольлек (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына кертелгән; 593 номерлы ТР МК карары нигезендә «Татарстан Республикасы йогынты актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына кертелгән тиешле мәгълүмат» сүзләре белән алмаштырырга;

2 бүлектә:

2.1.2 пунктчадагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| ТР МК БВИ ДВИ ТБ аталышы | адресы | Телефон |
|---|---|---|
| ТР МК БВИ ДВИ Саба ТБ | 422060, ТР, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., Завод урамы, 19 | 8-843-622-53-78 |
| ТР МК БВИ ДВИ Апас ТБ | 422350, ТР, Апас районы, Апас ш.т.п., Совет ур., 5 | 8-843-762-15-63 |
| ТР МК БВИ ДВИ Алексеевск ТБ | 422980, ТР, Чистай ш., К.Маркс ур., 27 | 8-843-425-24-26 |
| ТР МК БВИ ДВИ Түбән Кама ТБ | 423570, ТР, Түбән Кама ш., Актүбә ур., 6А | 8-855-542-50-44 |
| ТР МК БВИ ДВИ Яр Чаллы ТБ | 423806, Яр Чаллы ш., ГЭС пос., Муса Җәлил пр., 56 | 8-855-270-15-83 |
| ТР МК БВИ ДВИ Әлмәт ТБ | 423452, ТР, Әлмәт ш., Клара Цеткин ур., 54а | 8-855-332-17-61 |
| ТР МК БВИ ДВИ Казан ТБ | 420111, ТР, Казан ш., Федосеев ур., 36 й. | 8-843-221-77-41 |

«

2.1.6 пунктта:

алтынчы, сигезенче абзацларны төшереп калдырырга;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зарури таләпләрне бозуны профилактикалау максатларында «Интернет» челтәрендә ТР МК БВИ рәсми сайтында түбәндәге мәгълүматлар урнаштырыла:»;

2.2 пунктның 2.2.1, 2.2.2 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2.1. 294-ФЗ номерлы федераль законның 11 һәм 12 статьяларында каралган тикшерүләрнең һәркайсын уздыру срогы егерме эш көненнән артык була алмый.

294-ФЗ номерлы федераль законның 11 һәм 12 статьяларында каралган Россия Федерациясенең берничә субъекты территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы юридик затка карата һәр тикшерүне уздыру вакыты юридик затның һәр филиалы, вәкиллеге, аерымланган структур бүлекчәсе өчен аерым билгеләнә, бу вакытта тикшерү уздыруның гомуми вакыты алтмыш эш көненнән артык була алмый.

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясенең бер резидентына карата планлы тикшерү уздыру срогы аны уздыра башлау датасыннан алып иң күбе унбиш эш көне тәшкил итә.

Кече эшкуарлыкның бер субъектына карата урынга чыгып планлы тикшерүләр үткәрүнең гомуми вакыты бер елга кече предприятие өчен илле сәгатьтән һәм микропредприятие өчен унбиш сәгатьтән артык була алмый.

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясенең бер резидентына карата урынга чыгып планлы тикшерүләр үткәрүнең гомуми вакыты бер елга кече предприятие өчен кырык сәгатьтән һәм микропредприятие өчен ун сәгатьтән артык була алмый.

Искәрмәле, катлаулы һәм (яисә) озак вакытлы тикшеренүләрне, махсус экспертизаларны һәм тикшерүләрне үткәрү зарурлыгына бәйле булган очракларда, ТР МК БВИнең урынга чыгып планлы тикшерүне үткәрүче вазыйфаи затларының нигезләнгән тәкъдимнәре ТР МК БВИ башлыгы тарафыннан озынайтылырга мөмкин, ләкин егерме эш көненнән дә артыграк чорга түгел, кече предприятиеләр өчен иң күбе – илле сәгатькә, микропредприятиеләр өчен иң күбе – унбиш сәгатькә.

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясенең бер резидентына карата тикшерү уздырылганда, тикшерү уздыручы ТР МК БВИ вазыйфаи затларының нигезле тәкъдимнәре нигезендә катлаулы һәм (яки) озак вакытлы махсус тикшеренүләрне һәм экспертизаларны уздыру зарурлыгына бәйле искәрмәле очракларда, тикшерү уздыру срогы озынайтыла, ләкин кече предприятиеләргә карата иң күбе ун эш көненә һәм микропредприятиеләргә карата иң күбе ун сәгатькә.

2.2.2. Төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге ТР Министрлар Кабинетының 2018 елның 27 сентябрендәге 856 номерлы карары нигезендә куркынычка юнәлтелгән алымны кулланып гамәлгә ашырыла. Планлы тикшерүләрне үткәрү ешлыгы юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлеген куркынычлылыкның билгеле бер категориясенә кертүгә карап билгеләнә.»;

2.2.3 пунктчаның беренче абзацында «2 нче абзацта» сүзләрен «дүртенче абзацта» сүзләренә алмаштырырга;

2.3 пунктның 2.3.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3.1. Планлы тикшерүләр ТР МК БВИ, ТР МК БВИ ТБ тарафыннан эшләнә һәм раслана торган юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга планлы тикшерүләр уздыруның еллык планнары (алга таба – План) нигезендә уздырыла.

ТР МК БВИ башлыгы тарафыннан расланган планнар «Интернет» челтәрендә ТР МК БВИ рәсми сайтында урнаштырыла.

Ел саен уздырыла торган тикшерүләр планы 294-ФЗ номерлы федераль законга һәм РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карарына ярашлы рәвештә, куркынычка юнәлтелгән алым кулланып эшләнә.

Төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашырганда куркынычка юнәлтелгән алым куллану максатларында юридик затларның, шәхси эшкуарларның эшчәнлеге һәм (яки) алар куллана торган җитештерү объектлары 563 номерлы ТР МК карарында билгеләнгән критерийлар нигезендә куркынычлылыкның билгеле бер категориясенә кертелергә тиеш.

Юридик затларның, шәхси эшкуарларның эшчәнлеген һәм (яки) алар куллана торган җитештерү объектларын билгеле бер куркынычлылык категориясенә кертү ТР МК БВИ тарафыннан, юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның зарури таләпләрне үтәмәү ихтималының потенциаль тискәре нәтиҗәләрен исәпкә алып һәм юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның зарури таләпләрне үтәмәү ихтималын бәяләп, гамәлгә ашырыла.

Юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлегенә куркынычлылыкның билгеле бер категориясе бирелмәсә, юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлеге куркынычның түбән дәрәҗәле категориясенә кертелгән булып санала.

Эшчәнлекләре куркынычлылык категорияләренең берсенә кертелгән юридик затның, шәхси эшкуарның соратуы буенча, ТР МК БВИ мондый сорату килгән датадан башлап 15 эш көненнән артмаган срокта, аларга үз эшчәнлегенә беркетелгән куркынычлылык категориясе турында мәгълүматны, шулай ук аларның эшчәнлеген куркынычлылыкның билгеле бер категорияләренә керткәндә файдаланылган белешмәләрне җибәрә.

Юридик зат яки шәхси эшкуар 806 номерлы РФ Хөкүмәте карарында билгеләнгән тәртиптә үз эшчәнлекләренә элегрәк бирелгән куркынычлылык категориясен үзгәртү турында ТР МК БВИ гариза бирергә хокуклы.

Бирелгән куркынычлылык категориясенә карап, төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге объектларына карата планлы тикшерүләр түбәндәге ешлык белән уздырыла:

гадәттән тыш куркынычлылык категориясе өчен - өч елга бер тапкыр;

югары куркынычлылык категориясе өчен - өч елга бер тапкыр;

уртача куркынычлылык категориясе өчен - дүрт елга бер тапкырдан ешрак түгел;

өлешчә куркынычлылык категориясе өчен - биш елга бер тапкырдан ешрак түгел;

түбән дәрәҗәле куркынычлылык категориясенә кертелгән төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге объектларына карата планлы тикшерүләр уздырылмый.

Юридик затны һәм шәхси эшкуарны планлы тикшерүне Ел саен уздырыла торган планлы тикшерүләр планына кертү нигезе булып билгеле бер куркынычлылык категориясе өчен билгеләнгән срокның бетүе тора:

1) юридик затны, шәхси эшкуарны дәүләт теркәвенә алган көннән башлап;

2) юридик затка, шәхси эшкуарга карата үткәрелгән соңгы планлы тикшерүне уздыру тәмамланган көннән башлап;

3) юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тиешле өлкәдә вәкаләтле дәүләт контроле (күзәтчелеге) органына эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турында тапшырылган хәбәргә ярашлы рәвештә, күрсәтелгән хәбәрне тапшыруны таләп итә торган эшләр башкарылган яисә хезмәтләр күрсәтелгән очракта, эшкуарлык эшчәнлеге гамәлгә ашырыла башлаган көннән башлап.

Эшчәнлекләре куркынычлылык категориясенә кертелгән юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны үзләренә карата планлы тикшерүләр уздырыла торган юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның исемлекләренә кертү ТР МК БВИ башлыгының яки аның урынбасарының юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның эшчәнлеген тиешле куркынычлылык категориясенә кертү турындагы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

2.3.2 пунктчаның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«в) товарларны маркировкалауга карата таләпләр бозылуы»;

2.3.3 пунктчада:
«2 нче абзацта» сүзләрен «өченче абзацта» сүзләре белән алмаштырырга;
«Әгәр мөрәҗәгатьтә яки гаризада бәян ителгән мәгълүмат, шушы Регламентның 2.3.2 пунктчасының 2 абзацына туры китереп, планнан тыш тикшерү үткәрүнең нигезе була алса, ТР МК БВИ вазыйфаи заты, аның мөрәҗәгатьнең яки гаризаның авторына карата нигезле шикләре булганда, мөрәҗәгать итүче затны билгеләү буенча гакыллы чаралар күрергә бурычлы.» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.3.5 пунктта:
«зарури таләпләр бозылуы турында яки» сүзләрен төшереп калдырырга;
«Беренчел тикшерү уздыру барышында чаралар күреләә» сүзләрен «Килгән мәгълүматка беренчел тикшерү уздырылганда чаралар күреләә» сүзләре белән алмаштырырга;

2.3.6 пунктта:
«зарури таләпләр бозылуы турында яки» сүзләрен төшереп калдырырга;
«2 нче абзацта» сүзләрен «өченче абзацта» сүзләре белән алмаштырырга;

3 бүлектә:
түбәндәге эчтәлекле 3.2-3.4 пунктлар өстәргә:
«3.2. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан зарури таләпләр бозылу очракларын кисәтү, зарури таләпләр бозылуга сәбәпче булган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны юкка чыгару максатларында, ТР МК БВИ, ел саен раслана торган бозуларны кисәтү программасына туры китереп, зарури таләпләр бозылуны кисәтү буенча чараларны гамәлгә ашыра.

3.3. Зарури таләпләр бозылуны профилактикалау максатларында ТР МК БВИ 294-ФЗ номерлы федераль законның 8.2 статьясының 5-7 өлешләрендә билгеләнгән очракларда һәм тәртипкә ярашлы рәвештә зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү бирә һәм юридик затка, шәхси эшкуарга зарури

таләпләр үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрергә һәм бу хакта мондый кисәтүдә билгеләнгән чорда ТР МК БВИ хәбәр итәргә тәкъдим итә.

3.4. Зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтүне төзү һәм җибәрү, мондый кисәтүгә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан ризасызлыклар белдерү һәм аларны ТР МК БВИ тарафыннан карау, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан ТР МК БВИ мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү РФ Хөкүмәтенең 166 номерлы карары белән расланган Зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтүне төзү һәм җибәрү, мондый кисәтүгә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан ризасызлыклар белдерү һәм аларны карау, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре

АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАР ИСЕМЛЕГЕ

5.1. Төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга планлы һәм планнан тыш тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла, алар документар тикшерү һәм (яки) урынга чыгып тикшерү формасында, зарури таләпләр бозылуны профилактикалау буенча чараларны оештыру һәм уздыру (әлеге Регламентның 2.1.6, 3.2-3.4 пунктлары), ачыкланган бозуларны чикләү һәм (яки) бетерү буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны күрү, зарури таләпләр үтәлешен системалы рәвештә күзәтү, юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан эшчәнлекләре гамәлгә ашырылганда зарури таләпләр үтәлешен анализлау һәм фаразлау (алга таба – системалы рәвештә күзәтү һәм анализлау) формасында уздырыла.

Төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыру түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

юридик затка, шәхси эшкуарга карата планлы документар тикшерү уздыру, зарури таләпләрнең ачыкланган бозулары буенча чаралар күрү;

юридик затка, шәхси эшкуарга карата урынга чыгып планлы тикшерү уздыру, зарури таләпләрнең ачыкланган бозулары буенча чаралар күрү;

юридик затка, шәхси эшкуарга карата планнан тыш документар тикшерү уздыру, зарури таләпләрнең ачыкланган бозулары буенча чаралар күрү;

юридик затка, шәхси эшкуарга карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү уздыру, зарури таләпләрнең ачыкланган бозулары буенча чаралар күрү;

системалы рәвештә күзәтү һәм анализлау.

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентларына карата төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге әлеге Регламент нигезендә һәм 473-ФЗ номерлы федераль законның 24 статьясында, РФ Хөкүмәтенең 1132 номерлы карарында, Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 817 номерлы боерыгында билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентларына карата планлы тикшерүләр дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан билгеләнгән тәртиптә уртак тикшерүләр рәвешендә уздырыла.

5.2. Дәүләт функциясен үтәүнең блок-схемасы шушы Регламентка 3 нче кушымтада китерелде.

5.3. Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда дәүләт функциясен үтәүне туктатып тору рөхсәт ителә.

## «ЮРИДИК ЗАТКА, ШӘХСИ ЭШКУАРГА КАРАТА ПЛАНЛЫ ДОКУМЕНТАР ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ, ЗАРУРИ ТАЛӘПЛӘРНЕҢ АЧЫКЛАНГАН БОЗУЛАРЫ БУЕНЧА ЧАРАЛАР КҮРҮ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

### АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАНЫ БАШЛАУ НИГЕЗЕ, АДМИНИСТРАТИВ ГАМӘЛЛӘР ТӘРТИБЕ

5.4. «Юридик затка, шәхси эшкуарга карата планлы документар тикшерү уздыру, зарури таләпләрнең ачыкланган бозулары буенча чаралар күрү» административ процедурасын башлап җибәрү өчен еллык План нигезендә юридик затка, шәхси эшкуарга карата планлы документар тикшерү уздыру срокларының килеп җитүе тора.

Тикшерүләрнең еллык Планы куркынычка юнәлдерелгән алымны кулланып эшләнә, бу вакытта төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге объектлары, әлеге Регламентның 2.3.1 пунктында күрсәтелгәнчә, 563 номерлы ТР МК карарында расланган критерийлар нигезендә билгеле бер куркынычлылык категориясенә кертелергә тиеш.

Еллык Планны әзерләү, шул исәптән аны прокуратура органнарына тапшыру һәм прокуратура органнары белән килештерү тәртибе һәм сроклары, шулай ук еллык Планның бертип формалары РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карары белән расланган Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан оешмаларга планлы тикшерүләр уздыруның еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрендә билгеләнгән.

«Юридик затка, шәхси эшкуарга планлы документар тикшерү уздыру, зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү буенча чаралар күрү» административ процедурасы административ гамәлләрнең түбәндәге тәртибенә ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла:

- тикшерүне үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү;
- тикшерү уздыру турында күрсәтмә (боерык) рәсмиләштерү;
- юридик затка, шәхси эшкуарга планлы тикшерүне үткәрү хакында хәбәр итү;
- тикшерүне үткәрү;
- тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү һәм зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү буенча чаралар күрү;
- тикшерү нәтиҗәләре турында тиешле мәгълүмат урнаштыру.

ТИКШЕРҮНЕ ҮТКӘРҮ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРНЫ БИЛГЕЛӘҮ

5.5. Еллык План нигезендә үз компетенцияләре кысаларында тикшерү үткәрүче ТР МК БВИ ТБ башлыклары юридик затка, шәхси эшкуарга тикшерү үткәрү өчен вәкаләт бирелгән вазыйфаи затларны һәм җаваплы башкаручыны билгели.

Үтәү вакыты: тикшерүне үткәрә башлар алдыннан ун эш көненнән дә соңга калмыйча.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшкуарга тикшерүне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән вазыйфаи затлар исемлеге һәм җаваплы башкаручы.

ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ ТУРЫНДА КҮРСӘТМӘ (БОЕРЫК) РӘСМИЛӘШТЕРҮ

5.6. Җаваплы башкаручы:

- Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган формада юридик затка, шәхси эшкуарга планлы документар тикшерү уздырылуы турында күрсәтмә (боерык) проектын әзерли;

- күрсәтмә (боерык) проектын имза салу өчен ТР МК БВИ башлыгына (башлык урынбасарына) юллый.

Үтәү вакыты: тикшерүне үткәрә башлар алдыннан җиде эш көненнән дә соңга калмыйча.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшкуарга карата документар тикшерү үткәрү турында ТР МК БВИ башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан имзаланган күрсәтмә (боерык).

ЮРИДИК ЗАТКА, ШӘХСИ ЭШКУАРГА ТИКШЕРҮ УЗДЫРЫЛУЫ ТУРЫНДА ХӘБӘР ИТҮ

5.7. Җаваплы башкаручы планлы тикшерүне үткәрә башлау турында ТР МК БВИ башлыгы (башлык урынбасары) күрсәтмәсенең (боерыгының) күчермәсен кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы җибәрү юлы белән һәм (яисә) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, шәхси эшкуарның электрон почта адресына җибәрелгән электрон документ рәвешендә, әгәр мондый адрес тиешенчә юридик затларның бердәм реестрында, шәхси эшкуарларларның бердәм дәүләт реестрында булса, яисә элегрәк юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан ТР МК БВИ тапшырылган булса, яисә бүтән үтемле ысул белән юридик затка, шәхси эшкуарга планлы тикшерү үткәреләчәге хакында хәбәр итә.

Юридик затка, шәхси эшкуарга – үзкөйләнешле оешма әгъзасына карата тикшерү үткәрелгән очракта җаваплы башкаручы шулай ук, планлы документар тикшерүне үткәргәндә аннан вәкил катнашу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, үзкөйләнешле оешмага хәбәр җибәрә.

Үтәү вакыты: тикшерүне үткәрә башлар алдыннан өч эш көненнән дә соңга калмыйча.

Гамәлнең нәтиҗәсе: планлы документар тикшерү уздыру турында юридик затка, шәхси эшкуарга җибәрелгән күрсәтмә (боерык) күчермәсе һәм үзкөйләнешле

оешмага (үзкөйләнешле оешма әгъзасына тикшерү уздырылган очракта) җибәрелгән хәбәр.

5.8. Юридик зат, шәхси эшкуар, күрсәтмә (боерык) күчермәсен алган мизгелдән башлап ун эш көне эчендә, ТР МК БВИ планлы документар тикшерү үткәрү турындагы күрсәтмәдә (боерыкта) күрсәтелгән документларны җибәрергә бурычлы.

Күрсәтелгән документлар мөһер (булган очракта) һәм, тиешенчә, шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең, бүтән вазыйфаи затының имзасы белән таныкланган күчермәләре рәвешендә тапшырыла.

Юридик зат, шәхси эшкуар гарызнамәдә күрсәтелгән документларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә дә тапшырырга хокуклы.

Әгәр Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаса, ТР МК БВИ тапшырыла торган документларның күчермәләрен нотариаль яктан таныклауны таләп итү рөхәт ителми.

ТР МК БВИ юридик заттан, шәхси эшкуардан ТР МК БВИ тарафыннан дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) бүтән органнарыннан, муниципаль контроль органнарыннан алынырга мөмкин булган белешмәләрне һәм документларны таләп итәргә хокуклы түгел.

ТР МК БВИ, тикшерүләрне оештырганда һәм уздырганда, түләүсез нигездә, шул исәптән электрон рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлеккә кертелгән документларны һәм (яисә) мәгълүматларны шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән чорларда һәм тәртиптә сората һәм ала.

ТИКШЕРҮНЕ ҮТКӘРҮ

5.9. Тикшерүне үткәрү өчен вәкаләт бирелгән вазыйфаи затлар ТР МК БВИ карамагында булган документлардагы белешмәләр һәм юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тапшырылган документлардагы белешмәләр нигезендә:

- белешмәләрнең дөрес булуына карата бәяләү үткәрә;

- документлардагы белешмәләрне юридик зат, шәхси эшкуар эшчәнлегенең билгеләнгән зарури таләпләргә туры килүе-килмәве предметы буенча бәяли.

Әгәр документар тикшерү барышында юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тапшырылган документларда хаталар һәм (яисә) каршылыклар булуы, яисә бу документларда булган мәгълүматларның ТР МК БВИ карамагында булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәве ачыкланса, җаваплы башкаручы:

- юридик затка, шәхси эшкуарга, белешмәләрне бәяләү нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат белән һәм ун эш көнендә язмача рәвештә кирәкле аңлатмаларны тапшыруын таләп итеп, хат (дәлилле гарызнамә) әзерли;

- хатны (нигезле гарызнамәне) имза салу өчен ТР МК БВИ башлыгына (башлык урынбасарына) юллый;

- имзаланганнан соң хатны (дәлилле гарызнамәне) юридик затның, шәхси эшкуарның адресына кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп яисә бүтән үтемле ысул белән (факимиль элемтә, электрон почта, кулга алу турында тамгасы белән кулга тапшырып) җибәрә.

ТР МК БВИ тапшырылган документларда ачыкланган хаталарга һәм (яки) каршылыкларга карата яисә бу документларда булган белешмәләрнең ТР МК БВИ карамагындагы документларның белешмәләренә туры килмәвенә карата аңлатмалар тапшыручы юридик зат, шәхси эшкуар ТР МК БВИ элегрәк тапшырылган документларның төгәл булуын раслый торган документларны өстәмә рәвештә тапшырырга хокуклы.

Элек тапшырылган документларның дөреслеген раслый торган аңлатмалар һәм (яисә) документлар алынганнан соң, тикшерүне үткәрү өчен вәкаләт бирелгән вазыйфаи затлар юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тапшырылган, элек тапшырылган документларның дөреслеген раслый торган аңлатмаларны һәм (яисә) документларны карап тикшерәләр һәм җаваплы зат тикшерү актын төзи.

Әгәр элегрәк тапшырылган документларның дөреслеген раслап тапшырылучы аңлатмалаларны һәм документларны карап тикшергәннән соң, яисә аңлатмалар аңлатмалар булмаганда ТР МК БВИ зарури таләпләрне бозу билгеләрен билгеләсә, ТР МК БВИ вазыйфаи затлары урынга чыгып тикшерү үткәрергә хокуклы, аны үткәргәндә юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән документар тикшерүне үткәргәндә алар тарафыннан тапшырылган документларны һәм (яки) мәгълүматны таләп итү рөхсәт ителми. Мондый очракта документар тикшерү нәтиҗәсе «Юридик затка, шәхси эшкуарга урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү, зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү буенча чаралар күрү» административ процедурасын башкаруны башлау нигезенә туры киләчәк.

Үтәү вакыты: әлеге Регламентның 2.2.1 п. нигезендә тикшерү уздыру турында күрсәтмәдә (боерыкта) билгеләнгән тикшерү уздыру срогы эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тапшырылган, карап тикшерелгән аңлатмалар һәм (яки) документлар; зарурлык булганда планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрү турында күрсәтмә (боерык) проекты.

## ТИКШЕРҮ НӘТИҖӘЛӘРЕН РӘСМИЛӘШТЕРҮ ҺӘМ ЗАРУРИ ТАЛӘПЛӘРНЕҢ АЧЫКЛАНГАН БОЗУЛАРЫН БЕТЕРҮ БУЕНЧА ЧАРАЛАР КҮРҮ

5.10. Тапшырылган документларны һәм мәгълүматларны карау нәтиҗәләре буенча җаваплы башкаручы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган формада ике нөсхәдә тикшерү актын төзи.

Контрольлек чаралары нәтиҗәсендә зарури таләпләрнең бозылуы ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы түбәндәге гамәлләрне башкара:

тикшерү актында ачыкланган бозуларның барлык очракларын да терки;

бетерү вакытларын күрсәтеп, ачыкланган бозуларны бетерү турында һәм кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә зыян салынуны, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә, дәүләти яисә муниципаль мөлкәткә булган зыянны туктату, табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүен

кисәтү буенча чаралар, шулай ук федераль законнарда каралган башка чараларны уздыру турында күрсәтмә әзерли һәм юридик затка, шәхси эшкуарга тапшыра;

ачыкланган бозуларны бетерү, аларны кисәтү, шулай ук ачыкланган бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрә;

Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 10.6, 10.7, 10.8 статьяларында, 19.5 статьясының 8 өлешендә каралган административ хокук бозу билгеләре ачыкланганда, административ хокук бозулар турында эшләр кузгата һәм аларның билгеләнгән тәртиптә каралуын тәэмин итә, административ җәза билгели һәм куллана;

Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 14.43, 14.44-14.46, 14.46.2 статьяларында, 19.4 статьясының 1 өлешендә, 19.5 статьясының 1 һәм 15 өлешләрендә каралган административ хокук бозу билгеләре ачыкланганда, административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзи һәм эшне карау өчен судка тапшыра;

саксызлык аркасында эпизотияләр таралуга яки башка төр катлаулы нәтиҗәләргә китергән, ветеринария кагыйдәләре бозылу өлешендә РФ ҖК 249 статьясының 1 өлешендә каралган ветеринария законнарын бозу очраклары ачыкланган очракта, прокурор исеменә гариза төзи һәм тикшерү актын тапшыра.

Үзкөйләнешле оешма әгъзаларының зарури таләпләрне бозулары ачыкланган очракта җаваплы башкаручы тикшерүне уздыру тәмамланган көннән соң биш эш көне эчендә ачыкланган бозулар турында үзкөйләнешле оешмага белдерүнамә җибәрә.

Контрольлек чарасы барышында контрольлек буенча чара уздыру объекты булып торган хуҗалык яисә бүтән эшчәнлекнең законнардагы таләпләрне бозуга бәйле икәнлеге ачыкланган очракта, аларны ачыклау, туктату һәм чикләү мәсьәләләре ТР МК БВИ компетенциясенә карамаса, ТР МК БВИ Россия Федерациясенең яисә Татарстан Республикасының тиешле вәкаләтле дәүләт хакимияте органнарына мондый бозулар турында мәгълүматларны (белешмәләрне) җибәрергә бурычлы.

Тикшерү актының бер нөсхәсен (кушымталарының күчермәләре белән берлектә) җаваплы башкаручы эшкә тегеп куя һәм аны ТР МК БВИ билгеләнгән тәртиптә тапшырганчыга кадәр саклый, икенчесен (кушымталарының күчермәләре белән берлектә) юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү акты белән танышып чыгу турында яисә танышып чыгудан баш тарту турында имза куйдыртып тапшыра.

Юридик затның җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яисә вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган затның тикшерү акты белән танышып чыгуы турында яисә танышып чыгудан баш тартуы турында имза куясы килмәсә, акт кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп җибәрелә, кулга алу турындагы белдерүнамә ТР МК БВИ эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә. Тикшерелә торган затның дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булган очракта, тикшерү акты юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә шушы актны төзегән затның көчәйтелгән

квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта шушы акты төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган, тикшерелүче затка күрсәтелгән документның алынуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән электрон документ рәвешендә җибәрелгән акт тикшерелүче зат тарафыннан алынган дип исәпләнә. Акт тапшыру турында хәбәр һәм (яки) башкача раслама ТР МК БВИ эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.

Үзләренә карата тикшерү үткәрелгән юридик зат, шәхси эшкуар, тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән яисә ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән риза булмаган очракта, тикшерү актын алган датадан соң унбиш көн эчендә ТР МК БВИ тикшерү актына һәм (яисә) ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмәгә карата тулаем яисә аның аерым нигезләмәләренә карата язмача рәвештә ризасызлыклар тапшырырга хокуклы. Шул ук вакытта юридик зат, шәхси эшкуар мондый ризасызлыкларга шушы ризасызлыкларның нигезле булуын раслый торган документларны яисә аларның таныкланган күчермәләрен теркәргә яисә аларны килешенгән вакытта ТР МК БВИ тапшырырга хокуклы. Күрсәтелгән документлар тикшерелә торган затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ (электрон документлар пакеты) рәвешендә дә җибәрелергә мөмкин.

Үтәү вакыты:

- тикшерү актын төзү һәм тапшыру: тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры (әгәр дә актны төзү өчен үткәрелгән тикшерүләрнең, сынауларның, махсус тикшеренүләрнең, экспертизаларның нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр алу зарури булса, тикшерү акты контроль буенча чаралар төгәлләнгәннән соң өч эш көненнән артмаган чорда төзелә);

- тикшерү актын заказлы хат итеп яки әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында җибәрү: тикшерү актын төзегәннән соң бер эш көне эчендә;

- тикшерү актын формалаштыру урыны буенча ТР МК БВИ структур бүлекчәсендә саклау: билгеләнгән тәртиптә аны ТР МК БВИ архивына тапшырганчыга кадәр норматив актларда билгеләнгән чорлар дәвамында.

Гамәлнең нәтиҗәсе: ике нөсхәдә төзелгән тикшерү акты, аның берсе юридик затка, шәхси эшкуарга тапшырылган (җибәрелгән), икенчесе эшкә теге куелган һәм билгеләнгән тәртиптә формалаштыру урыны буенча ТР МК БВИ структур бүлекчәсендә саклана.

5.11. Кузгатылган административ хокук бозу эшен карап тикшерү нәтиҗәләре буенча ТР МК БВИ тарафыннан түбәндәге карарларның берсе чыгарыла:

шушы Регламентка 4 нче кушымтада бирелгән форма буенча административ җәза билгеләү турында карар;

шушы Регламентка 5 нчы кушымтада бирелгән форма буенча административ хокук бозу эше буенча эш башкаруны туктату турында карар.

Үтәү вакыты: административ хокук бозу турында беркетмә төзелгән мизгелдән башлап унбиш көн дәвамында.

Гамәлнең нәтиҗәсе: административ хокук бозу эше буенча административ җәза билгеләү турында карар яисә административ хокук бозу эше буенча эшне туктату турында карар.

5.12. Җаваплы башкаручы административ хокук бозу эше буенча администиратив җәза билгеләү турында карар күчермәсен яисә административ хокук бозу эше буенча эшне туктату турында карар күчермәсен бу карар үзләренә карата чыгарылган физик затка, яисә физик затның законлы вәкиленә, яисә юридик затның законлы вәкиленә кул куйдыртып тапшыра, яисә күрсәтелгән затларга кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп җибәрә.

Үтәү вакыты: административ хокук бозу эше буенча администиратив җәза билгеләү турында карар яисә административ хокук бозу эше буенча эшне туктату турында карар чыгарылган көннән башлап өч көн эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затка яисә шәхси эшкуарга тапшырылган яки җибәрелгән административ хокук бозу эше буенча администиратив җәза билгеләү турында карар күчермәсе яисә административ хокук бозу эше буенча эшне туктату турында карар күчермәсе.

ТИКШЕРҮ НӘТИҖӘЛӘРЕ ТУРЫНДА ТИЕШЛЕ МӘГЪЛҮМАТ УРНАШТЫРУ

5.13. Административ процедура тәмамланганнан соң җаваплы башкаручы тиешле мәгълүматны планлы документар тикшерүне үтәү нәтиҗәләрен теркәү максатында, ТР МК БВИ рәсми сайтында урнаштыру өчен, ТР МК БВИ ветеринарлык эшен оештыру бүлегенә җибәрә.

Үтәү вакыты: мәгълүмат урнаштыру – тикшерү акты имзаланганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча.

Гамәлнең нәтиҗәсе: ТР МК БВИ рәсми сайтында урнаштырылган планлы документлар тикшерүне үтәү нәтиҗәләре турында мәгълүмат.

5.14. Җаваплы башкаручы РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә тикшерүләрнең бердәм реестрына, РФ Хөкүмәтенең 482 номерлы карары нигезендә «Контрольлек (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына, 593 номерлы ТР МК карары нигезендә «Татарстан Республикасы йогынты актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына тиешле мәгълүматны кертә.

## «ЮРИДИК ЗАТКА, ШӘХСИ ЭШКУАРГА КАРАТА УРЫНГА ЧЫГЫП ПЛАНЛЫ ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ, ЗАРУРИ ТАЛӘПЛӘРНЕҢ АЧЫКЛАНГАН БОЗУЛАРЫ БУЕНЧА ЧАРАЛАР КҮРҮ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

### АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАНЫ БАШЛАУ НИГЕЗЕ, АДМИНИСТРАТИВ ГАМӘЛЛӘР ТӘРТИБЕ

5.15. «Юридик затка, шәхси эшкуарга карата урынга чыгып планлы тикшерү уздыру, зарури таләпләрнең ачыкланган бозулары буенча чаралар күрү» административ процедурасын башлап җибәрү өчен еллык План нигезендә юридик затка, шәхси эшкуарга карата урынга чыгып планлы тикшерү уздыру срокларының

килеп җитүе тора, шулай ук документар тикшерү вакытында түбәндәгеләр мөмкин булмаса:

1) эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турындагы белдерүнамәдә һәм юридик затның, шәхси эшкуарның ТР МК БВИ карамагында булган бүтән документларында бәян ителгән белешмәләрнең тулы һәм дөрес булуын тикшереп белү;

2) юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлегенең зарури таләпләргә туры килүен контроль буенча тиешле чараларны үткәрмичә бәяләү.

«Юридик затка, шәхси эшкуарга карата урынга чыгып планлы тикшерү уздыру, зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү буенча чаралар күрү» административ процедурасы әлеге Регламентның 5.4 пунктында күрсәтелгән административ гамәлләр тәртибенә ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ ЗАТЛАРНЫ БИЛГЕЛӘҮ, ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ ТУРЫНДА КҮРСӘТМӘ (БОЕРЫК) РӘСМИЛӘШТЕРҮ, ЮРИДИК ЗАТКА, ШӘХСИ ЭШКУАРГА ТИКШЕРҮ УЗДЫРЫЛУЫ ТУРЫНДА ХӘБӘР ИТҮ

5.16. Тикшерүне үткәрү өчен вәкаләт бирелгән вазыйфаи затларны һәм җаваплы башкаручыны билгеләү, урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү турында күрсәтмә (боерык) әзерләү, юридик затка, шәхси эшкуарга урынга чыгып планлы тикшерү үткәреләчәге турында хәбәр итү, үзкөйләнешле оешма әгъзасына тикшерү уздырылган очракта, – үзкөйләнешле оешмага хәбәр итү әлеге Регламентның 5.3 пунктындагы 5.5-5.7 пунктларына туры китереп гамәлгә ашырыла.

ТИКШЕРҮНЕ ҮТКӘРҮ

5.17. ТР МК БВИнең тикшерү уздыручы вазыйфаи затлары юридик зат, шәхси эшкуар объектына килеп җиткәннән соң юридик зат җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә кул куйдыртып, бер үк вакытта хезмәт таныклыкларын күрсәтеп, тикшерү уздырылуы турында мөһер белән таныкланган күрсәтмә (боерык) күчермәсен тапшыра.

Тикшерелергә тиешле затларның таләбе буенча ТР МК БВИ вазыйфаи затлары үзләренең вәкаләтләрен раслау максатларында ТР МК БВИ турында, шулай ук экспертлар, эксперт оешмалары турында мәгълүмат бирергә бурычлы.

Юридик зат җитәкчесенең, бүтән вазыйфаи затының һәм вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең гозере буенча ТР МК БВИ вазыйфаи затлары тикшерелергә тиешле затларны контроль буенча чаралар үткәрүнең административ регламентлары һәм аларны юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан эшчәнлекләрен гамәлгә ашырганда файдаланыла торган объектларда үткәрү тәртибе белән таныштырырга бурычлы.

Тикшерү барышында ТР МК БВИ вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Регламентның 4 бүлегендә китерелгән, юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан ветеринария турында законнарда билгеләнгән зарури таләпләрнең үтәлүе турында йомгак ясау өчен әһәмиятле булган документлар тикшерелә.

Тикшерү уздыруга вәкаләт бирелгән вазыйфаи затлар юридик зат, шәхси эшкуар эшчәнлегенең әлеге Регламентның 3 бүлегендә китерелгән зарури

таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә, шул исәптән түбәндәгеләрне контрольдә тоту буенча киләсе чараларны уздыра:

- урынга чыгып тикшерү максатларына, бурычларына һәм предметына бәйле документлар белән таныша, әгәр урынга чыгып тикшерү уздыру өчен уздырылган документар тикшерү уздырганда мондый документлар бирелмәгән булса;

- юридик затлар, шәхси эшкуарлар эшчәнлеге барышында кулланыла торган объектларны (терлекләрне, продукцияне, биналарны, корылмаларны, төзелмәләрне, бүлмәләрне, җиһазларны, транспорт чараларын, йөкләрне, башка объектларны) тикшерә.

Экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре контрольлек буенча киләсе чараларны уздыра:

- терлекләрнең йогышлы, инвазион һәм йогышлы булмаган авырулар белән чирләп китүенең ветеринария өлкәсендә федераль һәм республика законнары бозылуга бәйле сәбәпләрен өйрәнә;

- терлекләр асраганда һәм үрчеткәндә салкын карауга бәйле терлекләр саны кимү сәбәпләрен өйрәнә;

- терлекләрнең йогышлы чирләре, агулану очраклары һәм башка төрле массакүләм авыру очракларының барлыкка килү һәм таралу сәбәпләрен ачыклый;

- карантин кертү режимының дөрес булу-булмавын һәм йогышлы һәм йогышлы булмаган массакүләм авыруларга каршы көрәшнең башка кагыйдәләрен билгели;

- терлекләрне асрау һәм ашату кагыйдәләре, терлекчелектә барлыкка килгән продукцияне саклау һәм файдалану кагыйдәләре, табигатьне һәм хайваннарын дөньясын саклау турында РФ законнары нигезендә кыргый фаунаны һәм флораны саклау һәм торгызу кагыйдәләре бозылуны ачыклый.

Зарурлык булганда, тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар әлеге Регламентның 1.6.1 пунктының 5 пунктчасы таләпләре нигезендә, билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән электрон формада да, документларны һәм (яки) мәгълүматларны сората һәм ала.

Дәүләт серен яисә закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләрдән торучы документларны һәм (яисә) мәгълүматларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында сорату тиешле белешмәләрне тикшерүнең юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлү фактын билгеләү зарурлыгы белән аңлатылган һәм күрсәтелгән белешмәләрне тапшыру федераль законда каралган булу шарты белән рөхсәт ителә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документларны һәм (яисә) мәгълүматларны бирү, аларны ачу, шул исәптән, 294-ФЗ номерлы федераль законда каралган очракларда, алар белән таныштыру Россия Федерациясенең дәүләт сере һәм законда саклана торган бүтән сер турында законнарындагы таләпләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Үтәү вакыты: әлеге Регламентның 2.2.1 п. нигезендә урынга чыгып планлы тикшерү уздыру турында күрсәтмәдә (боерыкта) билгеләнгән тикшерү уздыру срогы эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: контроль буенча үткәрелгән чаралар.

5.18. Әгәр шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затының булмавына бәйле рәвештә, яисә

юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан эшчәнлекнең фактта башкарылмавына бәйле рәвештә, шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затының бүтән төрле, тикшерүне үткәрү мөмкинлеген юкка чыгаручы гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында планлы яки урынга чыгып планнан тыш тикшерүне үткәрү мөмкин булмаса, ТР МК БВИ вазыйфаи заты, аны үткәрү мөмкинлеген юкка чыгаручы сәбәпләрне күрсәтеп, тиешле тикшерүне үткәрү мөмкинлегенең булмавы хакында акт төзи. Бу очракта ТР МК БВИ, тиешле тикшерүне үткәрү мөмкинлегенең булмавы хакында акт төзелгән көннән башлап өч ай дәвамында, мондый юридик затка, шәхси эшкуарга карата, планлы тикшерүне еллык планлы тикшерүләр планына кертмичә һәм юридик затка, шәхси эшкуарга алдан хәбәр итмичә, урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы.

## ТИКШЕРҮ НӘТИҖӘЛӘРЕН РӘСМИЛӘШТЕРҮ ҺӘМ ЗАРУРИ ТАЛӘПЛӘРНЕҢ АЧЫКЛАНГАН БОЗУЛАРЫН БЕТЕРҮ БУЕНЧА ЧАРАЛАР КҮРҮ

5.19. Җаваплы башкаручы үткәрелгән контрольлек чаралары нигезендә РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча ике нөсхәдә тикшерү актын төзи.

Тикшерү актына түбәндәгеләр теркәлә:

продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм җитештерү тирәлеге объектларын тикшерү пробаларын сайлап алу беркетмәләре;

үткәрелгән тикшерүләрнең, сынауларның һәм экспертизаларның беркетмәләре яисә бәяләмәләре;

юридик затның, шәхси эшкуарның зарури таләпләрне бозган өчен җаваплылык йөкләнгән хезмәткәрләреннән аңлатмалары;

тикшерү нәтиҗәләренә бәйле булган бүтән документлар яисә аларның күчермәләре.

Тикшерү актының бер нөсхәсен (кушымталарының күчермәләре белән берлектә) җаваплы башкаручы эшкә теге куя һәм аны ТР МК БВИ билгеләнгән тәртиптә тапшырганчыга кадәр саклый, икенчесен (кушымталарының күчермәләре белән берлектә) юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү акты белән танышып чыгу турында яисә танышып чыгудан баш тарту турында имза куйдыртып тапшыра.

Юридик затның җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яисә вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган затның тикшерү акты белән танышып чыгуы турында яисә танышып чыгудан баш тарту турындагы имза куясы килмәсә, акт кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп җибәрелә, кулга алу турындагы белдерү ТР МК БВИ ТБ эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә. Тикшерелә торган затның дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булган очракта, тикшерү акты юридик зат җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә

җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган, тикшерелүче затка күрсәтелгән документның алынуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән электрон документ рәвешендә җибәрелгән акт тикшерелүче зат тарафыннан алынган дип исәпләнә. Актны тапшыру турында хәбәр һәм (яки) башкача раслама ТР МК БВИ ТБ эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.

Әгәр тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшеренүләрнең, сынауларның, махсус тикшерүләрнең, экспертизаларның бәяләмәсен алу кирәк булса, тикшерү акты контрольлек чараларын тәмамлаганнан соң өч эш көненнән артып китмәгән чорда төзелә һәм юридик зат җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә кул куйдыртып тапшырыла яисә кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы итеп җибәрелә һәм (яисә) шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә (тикшерелүче затның дәүләт контроле (күзәтчелеге) яки муниципаль контроль кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүне гамәлгә ашыруга ризалыгы булган очракта), күрсәтелгән документның алынуын тәэмин итүче ысул белән җиткерелә. Бу вакытта кулга тапшыру турыда хәбәр һәм (яисә) күрсәтелгән документның алынуына бүтәнчә дәлилләмә тикшерү актының ТР МК БВИ ТБ саклана торган эштәге нөсхәсенә теркәп куела.

Үзләренә карата тикшерү үткәрелгән юридик зат, шәхси эшкуар, тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән яисә ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән риза булмаган очракта, тикшерү актын алган датадан соң унбиш көн эчендә ТР МК БВИ тикшерү актына һәм (яисә) ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмәгә карата тулаем яисә аның аерым нигезләмәләренә карата язмача рәвештә ризасызлыклар тапшырырга хокуклы. Шул ук вакытта юридик зат, шәхси эшкуар мондый ризасызлыкларга шушы ризасызлыкларның нигезле булуын раслый торган документларны яисә аларның таныкланган күчермәләрен теркәргә яисә аларны килешенгән вакытта ТР МК БВИ тапшырырга хокуклы. Күрсәтелгән документлар тикшерелә торган затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ (электрон документлар пакеты) рәвешендә дә җибәрелергә мөмкин.

Үтәү вакыты:

- тикшерү актын төзү һәм тапшыру: тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры (әгәр актны төзү өчен үткәрелгән тикшерүләрнең, сынауларның, махсус тикшеренүләрнең, экспертизаларның нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр алу зарур булса, тикшерү акты контрольлек чаралары төгәлләнгәннән соң өч эш көненнән артмаган чорда төзелә);

- тикшерү актын заказлы хат итеп яки әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында җибәрү: тикшерү актын төзегәннән соң бер эш көне эчендә;

- тикшерү актын формалаштыру урыны буенча ТР МК БВИ структур бүлекчәсендә саклау: билгеләнгән тәртиптә аны ТР МК БВИ архивына тапшырганчыга кадәр норматив актларда билгеләнгән чорлар дәвамында.

Гамәлнең нәтиҗәсе: ике нөсхәдә төзелгән тикшерү акты, аның берсе юридик затка, шәхси эшкуарга тапшырылган (җибәрелгән), икенчесе эшкә теген куелган һәм билгеләнгән тәртиптә формалаштыру урыны буенча ТР МК БВИ структур бүлекчәсендә саклана.

5.20. Зарури таләпләр бозылу ачыкланган очракта җаваплы башкаручы ачыкланган бозуларны бетерү, аларны кисәтү, шулай ук гаепле затларны административ җаваплылыкка тарту буенча әлеге Регламентның 5.10-5.12 пунктлары нигезендә чаралар күрә.

Үзкөйләнешле оешма әгъзаларының зарури таләпләрне бозуы ачыкланган очракта җаваплы башкаручы тикшерүне уздыру тәмамланган көннән соң биш эш көне эчендә ачыкланган бозулар турында үзкөйләнешле оешмага белдерү җибәрә.

ТИКШЕРҮ НӘТИҖӘЛӘРЕ ТУРЫНДА ТИЕШЛЕ МӘГЪЛҮМАТ УРНАШТЫРУ

5.21. Җаваплы башкаручы юридик затның, шәхси эшкуарның тикшерүләрне исәпкә алу журналында (булган очракта) урынга чыгып үткәрелгән планлы тикшерү турында, дәүләт контроле (күзәтчелеге) органының аталышы, тикшерүне үткәрә башлау һәм тәмамлау даталары, аны үткәрү вакытлары, тикшерүнең төре, тикшерүнең хокукый нигезләре, максатлары, бурычлары һәм предметы, ачыкланган бозулар һәм бирелгән күрсәтмәләр турында белешмәләрне үз эченә алган язуны терки, шулай ук тикшерүне үткәргән вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм аларның имзалары күрсәтелә.

Үтәү вакыты: тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затның, шәхси эшкуарның тикшерүләрне исәпкә алу журналында (ул булган очракта) урынга чыгып үткәрелгән планлы тикшерү турында теркәлгән язу.

5.22. Административ процедура тәмамланганнан соң җаваплы башкаручы тиешле мәгълүматны урынга чыгып планлы тикшерүне үтәү нәтиҗәләрен теркәү максатында, ТР МК БВИ рәсми сайтында урнаштыру өчен, ТР МК БВИ ветеринарлык эшен оештыру бүлегенә җибәрә.

Үтәү вакыты: мәгълүмат урнаштыру – тикшерү акты имзаланганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча.

Гамәлнең нәтиҗәсе: ТР МК БВИ рәсми сайтында урнаштырылган урынга чыгып планлы тикшерүне үтәү нәтиҗәләре турында мәгълүмат.

5.23. Җаваплы башкаручы РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә тикшерүләрнең бердәм реестрына, РФ Хөкүмәтенең 482 номерлы карары нигезендә «Контрольлек (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына, 593 номерлы ТР МК карары нигезендә «Татарстан Республикасы йогынты актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына тиешле мәгълүматны кертә.

«ЮРИДИК ЗАТКА, ШӘХСИ ЭШКУАРГА КАРАТА ПЛАННАН ТЫШ ДОКУМЕНТАР ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ, АЧЫКЛАНГАН БОЗУЛАР БУЕНЧА ЧАРАЛАР КҮРҮ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАНЫ БАШЛАУ НИГЕЗЕ, АДМИНИСТРАТИВ ГАМӘЛЛӘР ТӘРТИБЕ

5.24. «Юридик затка, шәхси эшкуарга карата планнан тыш документар тикшерү уздыру, ачыкланган бозулар буенча чаралар күрү» административ процедурасын башлап җибәрү өчен әлеге Регламентның 2.3.2 пунктындагы 1, 2 «в», 3 пунктчаларында күрсәтелгән очраклар нигез булып тора.

«Юридик затка, шәхси эшкуарга карата планнан тыш документар тикшерү уздыру, зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү буенча чаралар күрү» административ процедурасы әлеге Регламентның 5.4 пунктында күрсәтелгән административ гамәлләр тәртибенә ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

ТИКШЕРҮНЕ ҮТКӘРҮ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРНЫ БИЛГЕЛӘҮ

5.25. ТР МК БВИ башлыгы (башлык урынбасары) ТР МК БВИ ДВИ ТБ хезмәткәрләре арасыннан юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш тикшерү уздыру турында ТР МК БВИ күрсәтмәләре (боерыклары) проектларын әзерләү өчен җаваплы башкаручыны билгели.

Үтәү вакыты: түбәндәгеләрдән соң бер эш көне:

- зарури таләпләр бозылуның ачыкланган очрагын юкка чыгару турында элегрәк бирелгән күрсәтмәнең юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан үтәлү вакыты узуы;

- әлеге Регламентның 2.3.2 пунктының 2 «в» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрнең һәм гаризаларның ТР МК БВИ килүе;

- Россия Федерациясе Президентының, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең планнан тыш тикшерүләр уздыру турындагы йөкләмәләре алыну.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш документар тикшерүне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән вазыйфаи затларның исемлеге һәм җаваплы башкаручы.

ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ ТУРЫНДА КҮРСӘТМӘ (БОЕРЫК) РӘСМИЛӘШТЕРҮ

5.26. Юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш тикшерү уздыру турында ТР МК БВИ башлыгы (башлык урынбасары) күрсәтмәсен (боерыгын) әзерләү әлеге Регламентның 5.6 пунктында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Үтәү вакыты: планнан тыш тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар билгеләнгәннән соң өч эш көне эчендә, яки йөкләмәдә күрсәтелгән срокка ярашлы рәвештә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшкуарга карата планнан тыш тикшерү үткәрү турында ТР МК БВИ башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан имзаланган күрсәтмә (боерык).

ЮРИДИК ЗАТКА, ШӘХСИ ЭШКУАРГА ТИКШЕРҮ УЗДЫРЫЛУЫ ТУРЫНДА ХӘБӘР ИТҮ

5.27. Җаваплы башкаручы юридик затка, шәхси эшкуарга әлеге Регламентның 5.37 п. нигезендә планнан тыш тикшерү уздырылуы турында хәбәр итә.

5.28. Юридик зат, шәхси эшкуар, күрсәтмә (боерык) күчермәсен алган мизгелдән башлап ун эш көне эчендә, ТР МК БВИ планнан тыш документар тикшерү үткәрү турындагы күрсәтмәдә (боерыкта) күрсәтелгән документларны җибәрергә бурычлы.

Күрсәтелгән документлар мөһер (булган очракта) һәм, тиешенчә, шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең, бүтән вазыйфаи затының имзасы белән таныкланган күчермәләре рәвешендә тапшырыла. Юридик зат, шәхси эшкуар гарызнамәдә күрсәтелгән документларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә дә тапшырырга хокуклы.

Әгәр Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаса, ТР МК БВИ тапшырыла торган документларның күчермәләрен нотариаль яктан таныклауны таләп итү рөхсәт ителми.

ТР МК БВИ юридик заттан, шәхси эшкуардан ТР МК БВИ тарафыннан дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) бүтән органнарыннан, муниципаль контроль органнарыннан алынырга мөмкин булган белешмәләрне һәм документларны таләп итәргә хокуклы түгел.

ТР МК БВИ, тикшерүләрне оештырганда һәм уздырганда, түләүсез нигездә, шул исәптән электрон рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлеккә кертелгән документларны һәм (яисә) мәгълүматларны шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән чорларда һәм тәртиптә сората һәм ала.

ТИКШЕРҮНЕ ҮТКӘРҮ

5.29. Юридик зат, шәхси эшкуар документларында булган белешмәләрне бәяләү, тапшырылган документлардагы кисәтүләргә каршы юридик затның, шәхси эшкуарның аңлатмаларын карап тикшерү шушы Регламентның 5.9 пунктында билгеләнгән тәртиптә тикшерү уздырылган вакытта гамәлгә ашырыла.

Үтәү вакыты: әлеге Регламентның 2.2.1 п. нигезендә тикшерү уздыру турында күрсәтмәдә (боерыкта) билгеләнгән тикшерү уздыру срогы эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан бирелгән аңлатмаларның һәм (яки) документларның карап тикшерелгәнлеге.

ТИКШЕРҮ НӘТИҖӘЛӘРЕН РӘСМИЛӘШТЕРҮ ҺӘМ ЗАРУРИ ТАЛӘПЛӘРНЕҢ АЧЫКЛАНГАН БОЗУЛАРЫН БЕТЕРҮ БУЕНЧА ЧАРАЛАР КҮРҮ

5.30. Тапшырылган документларны һәм мәгълүматларны карау нәтиҗәләре буенча җаваплы башкаручы әлеге Регламентның 5.10 п. нигезендә ике нөсхәдә

Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган формада тикшерү актын төзи.

5.31. Зарури таләпләр бозылу ачыкланган очракта җаваплы башкаручы ачыкланган бозуларны бетерү, аларны кисәтү, шулай ук гаепле затларны административ җаваплылыкка тарту буенча әлеге Регламентның 5.10-5.12 пунктлары нигезендә чаралар күрә.

Үзкөйләнешле оешма әгъзаларының зарури таләпләрне бозулары ачыкланган очракта җаваплы башкаручы тикшерүне уздыру тәмамланган көннән соң биш эш көне эчендә ачыкланган бозулар турында үзкөйләнешле оешмага белдерүнамә җибәрә.

ТИКШЕРҮ НӘТИҖӘЛӘРЕ ТУРЫНДА ТИЕШЛЕ МӘГЪЛҮМАТ УРНАШТЫРУ

5.32. Административ процедура тәмамланганнан соң җаваплы башкаручы тиешле мәгълүматны планнан тыш документар тикшерүне үтәү нәтиҗәләрен теркәү максатында, ТР МК БВИ рәсми сайтында урнаштыру өчен, ТР МК БВИ ветеринарлык эшен оештыру бүлегенә җибәрә.

Үтәү вакыты: мәгълүмат урнаштыру – тикшерү акты имзаланганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча.

Гамәлнең нәтиҗәсе: ТР МК БВИ рәсми сайтында урнаштырылган планнан тыш документлар тикшерүне үтәү нәтиҗәләре турында мәгълүмат.

5.33. Җаваплы башкаручы РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә тикшерүләрнең бердәм реестрына, РФ Хөкүмәтенең 482 номерлы карары нигезендә «Контрольлек (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына, 593 номерлы ТР МК карары нигезендә «Татарстан Республикасы йогынты актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына тиешле мәгълүматны кертә.

## «ЮРИДИК ЗАТКА, ШӘХСИ ЭШКУАРГА КАРАТА УРЫНГА ЧЫГЫП ПЛАННАН ТЫШ ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ, АЧЫКЛАНГАН БОЗУЛАР БУЕНЧА ЧАРАЛАР КҮРҮ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

### АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАНЫ БАШЛАУ НИГЕЗЕ, АДМИНИСТРАТИВ ГАМӘЛЛӘР ТӘРТИБЕ

5.34. «Юридик затка, шәхси эшкуарга карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү уздыру, ачыкланган бозулар буенча чаралар күрү» административ процедурасын башлап җибәрү өчен әлеге Регламентның 2.3.2 пунктында күрсәтелгән очраклар нигез булып тора, шулай ук документар тикшерү барышында түбәндәгеләр мөмкин булмаса:

1) эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турындагы белдерүнамәдә һәм юридик затның, шәхси эшкуарның ТР МК БВИ карамагында булган бүтән документларында бәян ителгән белешмәләрнең тулы һәм дөрес булуын тикшереп белү;

2) юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлегенең зарури таләпләргә туры килүен контроль буенча тиешле чараларны үткәрмичә бәяләү.

«Юридик затка, шәхси эшкуарга карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү уздыру, зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү буенча чаралар күрү» административ процедурасы әлеге Регламентның 5.4 пунктында күрсәтелгән административ гамәлләр тәртибенә ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

ТИКШЕРҮНЕ ҮТКӘРҮ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ БУЛГАН ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРНЫ БИЛГЕЛӘҮ

5.35. Тикшерү уздыруга вәкаләтле җаваплы башкаручыны, вазыйфаи затларны билгеләү әлеге Регламентның 5.25 пунктына ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ ТУРЫНДА КҮРСӘТМӘ (БОЕРЫК) РӘСМИЛӘШТЕРҮ

5.36. Юридик затка, шәхси эшкуарга урынга чыгып планнан тыш тикшерү уздыру турында ТР МК БВИ башлыгы (башлык урынбасары) күрсәтмәсен (боерыгын) әзерләү әлеге Регламентның 5.26 пунктында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

ЮРИДИК ЗАТКА, ШӘХСИ ЭШКУАРГА ТИКШЕРҮ УЗДЫРЫЛУЫ ТУРЫНДА ХӘБӘР ИТҮ

5.37. Җаваплы башкаручы юридик затка, шәхси эшкуарга урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәреләчәге турында, шушы Регламентның 2.3.2 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләрдә үткәрелә торган урынга чыгып планнан тыш тикшерүдән кала, теләсә нинди үтемле ысул белән, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, шәхси эшкуарның электрон почта адресына җибәрелгән электрон документ рәвешендә хәбәр итә, әгәр мондый адрес тиешенчә юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында булса, яисә элегрәк юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан дәүләт контроле (күзәтчелеге) органына, муниципаль контроль органына тапшырылган булса.

Юридик затка, шәхси эшкуарга карата үткәрү нигезләре әлеге Регламентның 2.3.2 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән урынга чыгып планнан тыш тикшерү уздыруны прокуратура органы белән килештерү турында гариза Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган гарзинаның бертип формасына туры китереп төзелә.

Юридик затка, шәхси эшкуарга – үзкөйләнешле оешма әгъзасына карата тикшерү үткәрелгән очракта җаваплы башкаручы шулай ук, планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрелгәндә аннан вәкил катнашу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, үзкөйләнешле оешмага хәбәр җибәрә.

Үтәү вакыты: тикшерүне үткәрә башлаганчыга кадәр егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздырылуы турында җибәрелгән хәбәр (һәм, үзкөйләнешле оешма әгъзасына тикшерү уздырылган очракта, үзкөйләнешле оешмага җибәрелгән хәбәр).

ТИКШЕРҮНЕ ҮТКӘРҮ

5.38. Урынга чыгып тикшерү үткәрү шушы Регламентның 5.17 пунктында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Үтәү вакыты: әлеге Регламентның 2.2.1 п. нигезендә урынга чыгып планлы тикшерү уздыру турында күрсәтмәдә (боерыкта) билгеләнгән тикшерү уздыру срогы эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: контроль буенча үткәрелгән чаралар.

5.39. Әгәр урынга чыгып планнан тыш тикшерүне уздыру әлеге Регламентның 5.18 пунктында күрсәтелгән сәбәпләр аркасында мөмкин булмаса, җаваплы башкаручы сәбәпләрен күрсәтеп, аны уздыруның мөмкин булмавы турында акт төзи һәм әлеге Регламентның 5.18 пунктына туры китереп, гамәлләр башкара.

ТИКШЕРҮ НӘТИҖӘЛӘРЕН РӘСМИЛӘШТЕРҮ ҺӘМ ЗАРУРИ ТАЛӘПЛӘРНЕҢ АЧЫКЛАНГАН БОЗУЛАРЫН БЕТЕРҮ БУЕНЧА ЧАРАЛАР КҮРҮ

5.40. Тикшерү актын төзү, тикшерү актын юридик затка, шәхси эшкуарга бирү әлеге Регламентның 5.19 пунктына ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

Үтәү вакыты:

- тикшерү актын төзү һәм тапшыру: тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры (әгәр дә актны төзү өчен үткәрелгән тикшерүләрнең, сынауларның, махсус тикшеренүләрнең, экспертизаларның нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр алу зарур булса, тикшерү акты контроль буенча чаралар төгәлләнгәннән соң өч эш көненнән артмаган чорда төзелә);

- тикшерү актын заказлы хат итеп яки әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында җибәрү: тикшерү актын төзегәннән соң бер эш көне эчендә;

- тикшерү актын формалаштыру урыны буенча ТР МК БВИ структур бүлекчәсендә саклау: билгеләнгән тәртиптә аны ТР МК БВИ архивына тапшырганчыга кадәр норматив актларда билгеләнгән чорлар дәвамында.

Гамәлнең нәтиҗәсе: ике нөсхәдә төзелгән тикшерү акты, аның берсе юридик затка, шәхси эшкуарга тапшырылган (җибәрелгән), икенчесе эшкә тегеп куелган һәм билгеләнгән тәртиптә формалаштыру урыны буенча ТР МК БВИ структур бүлекчәсендә саклана.

5.41. Зарури таләпләр бозылу ачыкланган очракта җаваплы башкаручы ачыкланган бозуларны бетерү, аларны кисәтү, шулай ук гаепле затларны административ җаваплылыкка тарту буенча әлеге Регламентның 5.10-5.12 пунктлары нигезендә чаралар күрә.

Үзкөйләнешле оешма әгъзаларының зарури таләпләрне бозулары ачыкланган очракта җаваплы башкаручы тикшерүне уздыру тәмамланган көннән соң биш эш көне эчендә ачыкланган бозулар турында үзкөйләнешле оешмага белдерүнамә җибәрә.

ТИКШЕРҮ НӘТИҖӘЛӘРЕ ТУРЫНДА ТИЕШЛЕ МӘГЪЛҮМАТ УРНАШТЫРУ

5.42. Җаваплы башкаручы юридик затның, шәхси эшкуарның тикшерүләрне исәпкә алу журналында (ул булган очракта) урынга чыгып үткәрелгән планнан тыш тикшерү турында, дәүләт контроле (күзәтчелеге) органының аталышы, тикшерүне үткәрә башлау һәм тәмамлау даталары, аны үткәрү вакытлары, тикшерүнең төре, тикшерүнең хокукый нигезләре, максатлары, бурычлары һәм предметы, ачыкланган бозулар һәм бирелгән күрсәтмәләр турындагы белешмәләрне үз эченә алган язуны терки, шулай ук тикшерүне үткәргән вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм аларның имзалары күрсәтелә.

Үтәү вакыты: тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затның, шәхси эшкуарның тикшерүләрне исәпкә алу журналында (ул булган очракта) урынга чыгып үткәрелгән планнан тыш тикшерү турында теркәлгән язу.

5.43. Административ процедура тәмамланганнан соң җаваплы башкаручы тиешле мәгълүматны урынга чыгып планнан тыш тикшерүне үтәү нәтиҗәләрен теркәү максатында, ТР МК БВИ рәсми сайтында урнаштыру өчен, ТР МК БВИ ветеринарлык эшен оештыру бүлегенә җибәрә.

Үтәү вакыты: мәгълүмат урнаштыру – тикшерү акты имзаланганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча.

Гамәлнең нәтиҗәсе: ТР МК БВИ рәсми сайтында урнаштырылган урынга чыгып планнан тыш тикшерүне үтәү нәтиҗәләре турында мәгълүмат.

5.44. Җаваплы башкаручы РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә тикшерүләрнең бердәм реестрына, РФ Хөкүмәтенең 482 номерлы карары нигезендә «Контрольлек (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына, 593 номерлы ТР МК карары нигезендә «Татарстан Республикасы йогынты актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына тиешле мәгълүматны кертә.

## «СИСТЕМАЛЫ РӘВЕШТӘ КҮЗӘТҮ ҺӘМ АНАЛИЗЛАУ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.45. Административ процедураны башлап җибәрү өчен юридик затларның, шәхси эшкуарларның эшчәнлекләрен гамәлгә ашырганда зарури таләпләрне үтәвенә системалы рәвештә күзәтү уздыруга, зарури таләпләр үтәлешенең торышын анализлауга һәм фаразлауга ТР МК БВИ башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан расланган йөкләмә (алга таба – йөкләмә) нигез булып тора.

5.46. Йөкләмәләрне рәсмиләштерү тәртибе һәм аларның эчтәлеге, системалы рәвештә күзәтү һәм анализлау нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибе ТР МК БВИ тарафыннан билгеләнә.

5.47. Системалы рәвештә күзәтү һәм анализ уздыруга җаваплы вазыйфаи затлар булып йөкләмәдә күрсәтелгән ТР МК БВИ вазыйфаи затлары тора.

5.48. Системалы рәвештә күзәтү һәм анализ уздыру срогы йөкләмәдә билгеләнә.

5.49. Йөкләмә түбәндәге зарури таләпләрнең бозылу билгеләре турында мәгълүматка нигезләнеп формалаштырыла:

а) ветеринария өлкәсендә РФ законнары таләпләренең бозылуы турында гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган;

б) тикшерүләрнең, шул исәптән зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү турында күрсәтмәләр үтәлешен тикшерүләрнең актларында, башка төр башкарма документларда булган;

в) үз вәкаләтләре кысаларында ТР МК БВИ гамәлгә ашыра торган мониторингны уздырганда алынган.

5.50. Системалы рәвештә күзәтү һәм анализлау чараларына түбәндәгеләр керә:

1) «Интернет» челтәрендә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмат урнаштырылганда зарури таләпләр үтәлешен күзәтү;

2) юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлеге яки гамәлләре турында федераль закон нигезендә әлеге затларга аны тапшыру җаваплылыгы йөкләнгән мәгълүматларны анализлау юлы белән зарури таләпләр үтәлешен күзәтү (шул исәптән федераль дәүләт мәгълүмат системаларыннан файдалану юлы белән).

5.51. Системалы рәвештә күзәткәндә һәм анализ ясаганда дәүләт ветеринария инспекторы:

1) юридик затларның, шәхси эшкуарларның исемлекләрен әзерли;

2) документларны һәм материалларны туплый;

3) документларны һәм материалларны эшкәртә һәм анализлый;

4) системалы рәвештә күзәтү һәм анализ ясау нәтиҗәләре буенча документлар әзерли.

5.52. Системалы рәвештә күзәтү һәм анализлау йомгаклары буенча дәүләт ветеринария инспекторы хисап әзерли.

5.53. Системалы рәвештә күзәтү һәм анализ үткәргәндә зарури таләпләрнең бозылу очраклары ачыкланган очракта, ТР МК БВИ вазыйфаи затлары үз компетенциясе чикләрендә мондый бозуларны чикләү буенча чаралар күрә, шулай ук, әлеге Регламентның 2.3.2 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш тикшерү билгеләү турында карар кабул итү зарурлыгы булганда, ачыкланган бозулар турында мәгълүматлар белән, ТР МК БВИ башлыгына (башлык урынбасарына) язмача рәвештә дәлилләнгән йогынты актын җибәрә.

5.54. Системалы рәвештә күзәтү һәм анализ үткәргәндә зарури таләпләрне бозуга әзерләнүләр яки бозу билгеләре турында белешмәләр алынган очракта, ТР МК БВИ юридик затка, шәхси эшкуарга әлеге Регламентның 3.3, 3.4 пунктларына ярашлы рәвештә зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү җибәрә.

5.55. Системалы рәвештә күзәтүнең һәм анализлауның нәтиҗәләре ТР МК БВИ тарафыннан планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне планлаштырганда һәм уздырганда файдаланыла.»;

7 бүлектә:

7.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.3. Судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне карауны туктатып тору яки

моннан баш тарту нигезләре каралмаган.

Әгәр язмача шикаятьтә юридик затның аталышы (мөрәҗәгать итүче юридик зат булганда), шикаятьне җибәргә мөрәҗәгать итүченең фамилиясе яки җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәсә, шикаятькә җавап бирелми. Әгәр дә күрсәтелгән шикаятьтә хокукка каршы килә торган гамәлнең әзерләнүе, кылынуы яки кылынганлыгы турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында белешмәләр булса, шикаять компетенциясенә ярашлы рәвештә дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

Суд карарына шикаять белдерелгән шикаять теркәлгән көненнән башлап җиде көн дәвамында, әлеге суд карарына шикаять белдерү тәртибен аңлатып, мөрәҗәгать итүчегә кире җибәрелә.

Әгәр язмача шикаятьтә цензурасын яки мыскыллау сүзләре, вазыйфаи затның, шулай ук аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар булса, ТР МК БВИ шикаятьне анда куелган мәсьәләләрнең асылы буенча җавапсыз калдырылырга хокуклы. Бу очракта шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хокуктан явызларча файдалануның ярамаганлыгы турында хәбәр ителә.

Әгәр язмача шикаятьнең тексты укылышлы булмаса, шикаятькә җавап бирелми, һәм ул карау өчен дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка аларның компетенцияләренә туры китереп җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта шикаятьне теркәү көненнән башлап җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, әгәр аның фамилиясе һәм почта адресы укылышлы булса.

Әгәр язмача шикаять тексты шикаятьнең асылын ачыкларга мөмкинлек бирмәсә, шикаятькә җавап бирелми һәм ул ул карау өчен дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка алар компетенциясенә туры китереп җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта мөрәҗәгатьне теркәүгә алган көннән соң җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән затка хәбәр ителә.

Әгәр язмача шикаятьтә аның асылы буенча, элек җибәрелгән шикаятьләргә бәйле рәвештә, инде берничә мәртәбә язмача җаваплар бирелгән сорау бәян ителгән булса һәм шул ук вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр яисә шартлар китерелмәсә, ТР МК БВИ башлыгы, ТР МК БВИ вазыйфаи заты яки моңа вәкаләтле заты, күрсәтелгән шикаятьнең һәм элек җибәрелгән шикаятьләрнең ТР МК БВИ яисә ТР МК ВБИ шул бер үк вазыйфаи затына җибәрелгән булуы шарты белән, чираттагы шикаятьнең нигезсез булуы һәм әлеге мәсьәлә буенча мөрәҗәгать итүче белән язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы. Әлеге карар турында шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

ТР МК БВИгә яки ТР МК БВИ вазыйфаи затына, 59-ФЗ номерлы федераль законның 10 статьясының 4 өлешенә туры китереп, ТР МК БВИ «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында җавабы урнаштырылган сорауны үз эченә алучы язмача шикаять килгән очракта, шикаятьне җибәрүче затка шикаятьне теркәүгә алган көннән соң җиде көн эчендә, шикаятьтә куелучы сораугa җавап урнаштырылган ТР МК БВИ рәсми сайтының электрон адресы турында хәбәр ителә, бу вакытта суд карарына шикаять белдерелә торган шикаять кире кайтарылмый.

Әгәр шикаятьтә күтәрелгән мәсьәләнең асылы буенча дәүләт серен яисә

федераль законда саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләрне таратмыйча җавап биреп булмаса, шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелгән белешмәләрне таратуның мөмкин булмавына бәйле рәвештә куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап бирү мөмкинлеге булмау турында хәбәр ителә.

Шикаятьтә күтәрелгән мәсьәләләрнең асылы буенча җавап бирү мөмкинлеге булмаган сәбәпләр алга таба бетерелсә, мөрәҗәгать итүче шикаятьне ТР МК БВИ яисә аның вазыйфаи затына кабат җибәрергә хокуклы.»;

7.6 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«7.6. Мөрәҗәгать итүченең шикаяте тиешле җитәкчегә буйсынганлык буенча тапшырыла.

ТР МК БВИ дәүләт ветеринария инспекциясе территориаль бүлегенең вәкаләтле вазыйфаи заты гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына шикаятьләр ТР МК БВИ дәүләт ветеринария инспекциясе территориаль бүлеге башлыгы тарафыннан карала.

ТР МК БВИ дәүләт ветеринария инспекциясе территориаль бүлеге башлыгы гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына шикаятьләр ТР МК БВИ башлыгы тарафыннан карала.

ТР МК БВИ башлыгы карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелергә мөмкин.».

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты
Баш ветеринария идарәсе башлыгы –
Татарстан Республикасы
Баш дәүләт ветеринария инспекторы А.Г. Хисаметдинов